Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Түбән Мәтәскә урта мәктәбе




# Проект эше:

# «Җиңү язы килде Җиргә кабат…»

## Бөек Җиңүгә багышлап иҗат ителгән шигырьләр

# Проектның авторы:

## ГАФФАРОВА ӘНИСӘ ӘНӘС КЫЗЫ

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә
Арча муниципаль районының ГабдуллаТукай исемендәге премиясе лауреаты – 2014 ел.
Татарстан Республикасының Туфан Миңнуллин исемендәге премиясе лауреаты – 2014 ел.
Әдәбият, мәдәният  һәм сәнгать өлкәсендә
Арча муниципаль районының Гариф Ахунов исемендәге премиясе лауреаты – 2015 ел.



# Проектның максаты һәм бурычлары:

**Бөек Җиңүгә багышлап иҗат**

**ителгән әсәрләрне туплау;**

**матбугат битләрендә яктырту;**

**төрле конкурсларда катнашу;**

**җыентык итеп бастырып чыгару;**

**музей сайтына урнаштыру.**

## Проектны тормышка ашыру вакыты:

**Апрель 2010**

**Май 2018**




# Проектның актуальлеге:

**_Бөек Ватан сугышы геройлары, ветераннары, сугыш чоры балаларының истәлекләрен саклау, барлау;_**

**_Аларның сугыш һәм хезмәт батырлыгы аша туган илгә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү._**

**_Ветераннарның истәлекләрен сайтка урнаштыру._**




# Җиңү язы килде җиргә кабат

*Җиңү язы килде җиргә кабат.*
*Уйга калам агымсуга карап:*
*Язгы судай ярларына тулып,*
*Күпме каннар аккан елга булып.*

*Җиңү язы килде җиргә кабат.*
*Тетрәп куям һәйкәлләргә карап:*
*Күпме гомерләрне сугыш өзгән,*
*Тол-ятимнәр, дим, ничек түзгән?*

*Җиңү язы килде җиргә кабат.*
*Сорау бирәм ятимнәргә карап:*
*Нинди иде кырык бишнең мае?*
*Ниләр алып килде язның ае?*

*Җиңү язы килде җиргә кабат.*
*Әби-бабайларның күңелен айкап.*
*Җавап бирде алар, яшькә тулып,*
*Җиңү таңы атты матур булып.*

*Җиңү язы килде җиргә кабат.*
*Теләк телим, зәңгәр күккә карап:*
*Кара болытлар, дим,*
*күренмәсен,*
*Хәсрәт яше җиргә түгелмәсен!*

*Җиңү язы килде җиргә кабат.*
*Чал чәчләрне назлы җилдә*
*тарап.*
*Явыз явызларга табынмасын,*
*Сугыш уты бүтән кабынмасын*

# Әбием – сугыш ятиме






Минем яраткан әбием-
Сугыш чоры баласы.
Аның тормыш юлын килә
Шигъри юлга саласы.
Мең тугыз йөз кырык өчнең
Матур апрель аенда
Дәү әни дөньяга килә
Күлтәс дигән авылда.
“Кызың туды” дигән хәбәр
Фронтка барып җитә.
Яу кырыннан Күлтәскә
Сәлам хаты тиз китә.
“Кызымның бәхете өчен
Канлы сугышка керәм,
Баламны күрәсем килә,
Исән калырмын, беләм.
Көтегез, сугышлардан
Исән-имин кайтырмын.
Сез горурлана алырлык
Көчле һәм дә батырмын”.
Өчпочмаклы солдат хаты-
Соңгы хәбәр. Кем белгән?
Хәбәрсез югалганнарны
Кемнәр соң барып күргән?

Сугыш бетә, җиңү килә,
Исән-сау кеше кайта.
Кемдер яралы йөрәкне
Каберен күреп юата.
Хәбәрсез югалганнарны
Көтеп күзләре тала.
Еллар үтә бер-бер артлы
Йөрәктә бары яра .
Җиденче сыйныфка кадәр
Әбием белем ала.
14 яше тулар-тулмас,
Фермада эшкә кала.
“Әтиле балаларга, -ди
Гел кызыгып яшәдем,
Әтиле булсам мин дә,
Укыган булыр идем.
Сезгә телим, балалар,
Ачы хәсрәт күрмәгез,
Тигез тормышта яшәгез,
Ятимлекне белмәгез”.
Әбиемнең теләкләре,
Амин, кабул булсыннар.
Җир йөзендәге кешеләр
Тыныч тормыш корсыннар.

# Сугыш чоры баласы -Галимҗанов Вәкил Шакирҗан улы.



1941 нче елның 8 нче январе.  Арча районы Иске Төрнәле авылында дүртенче бала булып минем дәү әтием Галимҗанов  Вәкил Шакирҗан улы дөньяга килә. Алты гына ай  әти һәм әни улларының матур булып үсүен күреп сөенеп кала, Бөек Ватан сугышы башланып китә. Әтисен сугышка алгач, әнисе көне - төне  тылда хезмәт иткән көннәрдә, дөньяның әчесен-төчесен күп күреп, тормышка чынлап та яраклашып үсә минем дәү әтием. Кулбашыннан ук бер кулын сугышта калдырып, контузия алып сугыштан кайткан әтисе, улын һөнәрле итәргә омтыла. Иске Төрнәле мәктәбен тәмамлагач, дәү әтием укуын  Үрнәк училищесында дәвам итә: механизатор һөнәрен үзләштерә.
1962 нче елдан 1994 нче елга кадәр бабамның хезмәт кенәгәсенә бер генә сүз язылган: “механизатор”. 32 ел чылбырлы тракторда эшли ул. Үз эшен шулкадәр яратып, намус белән башкарган кешеләрнең хезмәтенә сокланмый мөмкин түгел! Үз эшенең остасы булган, армый – талмый  хезмәт иткән иткән дәү әти белән чын йөрәктән горурланам мин.  1965 нче елда ук  Советлар Союзы Коммунистлар партиясе сафларына кабул ителгән 24 яшьлек егет үзен чын коммунистларча тота.  Бишьеллык планны вакытыннан  алда үтәү өчен ул үзенең көчен кызганмый. Хөкүмәт тә тырыш хезмәтне күреп, югары бәяләп килә. Алган орден – медальләре  маңгай тире тамызып, йокысыз төннәр үткәреп алган бүләкләре аның .  1973 нче елда социалистик ярышта җиңүче таныклыгы ала, 1975 нче елда  “Тугызынчы бишьеллык ударнигы” күкрәк билгесе белән бүләкләнә.


# Сугыш чоры баласы -Галимҗанов Вәкил Шакирҗан улы.



Социалистик Хезмәт Герое  Хастиев Мирбат Бәдри улы “Известия” колхозын җитәкләп, колхозның данын еракларга тарата. Тырыш кешеләре белән колхозны гөрләтеп алып бара ул, яңа хезмәт үрләре яулый. Шундый тырыш кешеләрнең берсе була да инде минем дәү әтием. Язгы-көзге эш вакытларында икешәр смена  эшли ул. Иртән генә эштән кайтып, бер-ике сәгать черем итеп алып, тагын эшкә китә.  Иң җаваплы эшләр тапшырыла аңа.  Иртә яздан җирләрне эшкәртә, чәчү чәчә,  сенаж , силос таптата һәм бервакытта да эшенә салкын карамый. Һәр көнне, һәр атнаны , һәр айны хезмәт алдынгыларын билгеләп бара торган вакыт була ул. Минем бабам беренчелекне бервакытта да бирми. 1978 нче елда III дәрәҗә Хезмәт даны ордены һәм кыйммәтле бүләк ала ул, ә 1986 нчы елда II дәрәҗә Хезмәт даны ордены белән бүләкләнә, Сочига ял итәргә путевка да бирәләр аңа. 1984 нче елда Казанга ВДНХ га барып, бронза медаль белән бүләкләнеп кайта ул.

“Мин бернинди дә батырлык эшләмәдем. Урман кисеп кайтканда, йөк ишелеп, бер аягымны имгәттем, шуңа күрә иптәшләрем белән бергә армия сафларында да хезмәт итә алмадым. Мин эшләдем генә. Эшли башлаган эшемне ахырына кадәр җиткерергә гадәтләнгән мин. Син дә, кызым, хезмәтне ярат. Хезмәтне яраткан кеше генә бу Җирдә бәхетле була ала,”- ди миңа дәү әтием.

# Мәктәп этнографик музееның сайты





Отечественная война
ТУКАЙ ВАРИСЛАРЫ
НАРАТ КАРГЫШЫ
Диплом
Диплом
ДИПЛОМ
Илһам чишмәсе
Такмаклар
Коррупция темасына такмаклар
Мин коррупциягә каршы
Задуши коррупцию!
Акча — хуҗа
ДИПЛОМ
ДИПЛОМ
Илһам
Алиш эзләреннән